Республика Татарстан
Глава
Ильбяковского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге
башлыгы

ул. А.Валеева, д. 53, село Ильбяково,
Азнакаевский район, 423321

Ә.Вәлиев урамы, 53нче йорт, Илбәк авылы,
Азнакай районы, 423321

Тел. (факс) 8(85592) 38-5-38; e-mail: Ilb.Azn@tatar.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
«18» ноябрь 2019 ел №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 елда кабул ителгән №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 28.07.2004 елда кабул ителгән №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, **карар чыгарам:**

1. 2019 елның 06 декабренә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 07 декабрь 2019 ел 10.00 сәг тән 11.00 сәг кә кадәр;
- үткәрү урыны – Илбәк авылы, Ә.Вәлиев ур., 50 йорт – Илбәк авылы мәдәният йорты дип билгеләргә.

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 28 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт;
- Илбәк торак пунктында сайлау хокукына ия булган яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән Ил торак пункты халкына гражданнарның җыены турында хәбәр итәргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2020 елда Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә я урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1төркем инвалидларыннан, Б Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышы катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында уку студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшь өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 150 су киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия бул түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Илбәк авылында бәйрәм чараларын (“Сабантуй”, Яңа ел” бәйрәмнәр үткәрү өчен хезмәтләр күрсәтү, бүләкләр һәм сувенир продукциясе сатып алу;

- Илбәк авылындагы урамнарны яктырту өчен энергияне саклый тор лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урам яктырту һәм ремо эшләре буенча хезмәтләр өчен түләү;

- Илбәк авылы мәдәният йорты өчен музыкаль аппаратура сатып алу;

- Илбәк авылындагы юлларны кардан чистарту;

- Илбәк авылы зираты өчен хуҗалык товарлары һәм инвентарь сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәс порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Интерн мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районы рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru һ Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а, Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йо адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Л.Р.Әсәдуллина